**СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

*Юрид. адрес: 423984, РТ, Муслюмовский район, с. Октябрь, ул. Молодежная, д.3а.*
*Факт. адрес: 423984, РТ, Муслюмовский район, с. Октябрь, ул. Центральная, д.33А.*
Okt.Mus@tatar.ru *тел. 8(8-5556) 3-51-26*
ИНН 1629001152, КПП 162901001, ОГРН 1021605557863, ОКАТО 92242860001

Октябрь авылы «16 » июль 2021 ел.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XVI УТЫРЫШЫ

**Карар№24**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Октябрь авыл җирлеге Советының 21.09.2020 нче елгы 4 нче номерлы карары белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе, Октябрь авыл җирлеге Уставы нигезендә, Октябрь авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү, җир эшләрен җитештерүгә рөхсәтләр бирү буенча төзекләндерү өлкәсендәге вәкаләтләрнең бер өлешен бирергә.
2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы Советына карау өчен җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә Мөслим муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 календарь көннән дә соңга калмыйча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзүгә Як булып чыгарга.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» Октябрь муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән соң үз көченә керә.
6. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Совет рәисе, Октябрь авыл җирлеге башлыгы** И.М.Ханнанов